МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

18.04.2018 Казан шәһәре № под-705/18

«Иң яхшы билингваль балалар бакчасы» гранты турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2018 елга Мәгариф өлкәсендә грантлар турында» 2018 елның 12 апрелендәге 238 номерлы карарының 1 пунктындагы икенче абзацын үтәү максатында мәктәпкәчә яшьтәге балаларга югары сыйфатлы билингваль белем бирүне тәэмин итүче мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының иң яхшы педагогик коллективларын ачыклау һәм бүләкләү максатларында б о е р а м:

1. «Иң яхшы билингваль балалар бакчасы» грантын гамәлгә кую (алга таба - Грант).

2. Грант турында тәкъдим ителгән Положениене расларга.

3. Гомуми белем бирү идарәсенә (Т. Т. Федорова) Грант турында Положениегә таянып грант алу өчен сайлап алу конкурсын оештырырга һәм үткәрергә:

читтән торып катнашу этабы-2018 елның 21 маеннан 3 июненә кадәр;

турыдан-туры сайлап алу этабы-2018 елның 4 июненнән 20 июненә кадәр.

4. Бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге (Г. К. Мөхәммәдкәримова) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган башка бюджетара трансфертлар рәвешендә, грант алу өчен конкурста җиңүчеләргә грантлар бирүгә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә акча күчерү эшен оештырырга.

5. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Министр вазыйфаларын
башкаручы И. Г. Һадиуллин

Расланган
Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгының
18.04.2018 № под-705/18
боерыгы белән

**«Иң яхшы билингваль балалар бакчасы» гранты турында**
**Положение**

## 1. Гомуми положениеләр

1.1. Әлеге Положение «Иң яхшы билингваль балалар бакчасы» грантының максатларын һәм бурычларын, грантта катнашучыларны , «Иң яхшы билингваль балалар бакчасы» Грантын алуга сайлап алуны оештыру һәм үткәрү тәртибен билгели (алга таба - конкурс сайлап алуы).

1.2. «Иң яхшы билингваль балалар бакчасы» (алга таба - грант) гранты Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән гамәлгә куела.

1.3. Грантта катнашучылар:

грант бирүче – грант бирү буенча вакәләтлренә ия булган Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба - министрлык);

грантка дәгъва кылучы – гамәлгә куючысы (учредителе) Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгы булган, Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән, билгеләнгән тәртиптә мәктәпкәчә белем бирү буенча гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмасы (алга таба- белем бирү оешмасы);

грант алучы-әлеге Положениедә билгеләнгән критерийларга һәм таләпләргә туры килә торган, конкурс сайлап алуын узган һәм 1-30 урынга чыккан белем бирү оешмасы.

1.4. Грант - Грант алучыларга, мәктәпкәчә төркемнәрнең сыйфатлы үстерешле предметлы-тирәлеген булдыру, педагогик коллективның һөнәри үстешенә юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру өчен, бер тапкыр бирелә торган, 500 000 (биш йөз мең) сум күләмендә акчалата бүләк.

Грант алучы 5 елга 1 тапкыр грантта катнашырга хокуклы

1.5. Конкурс сайлап алу максатлары:

Татарстан Республикасы дәүләт телләрен популярлаштыру;

мәктәпкәчә билингваль белем бирү буенча белем бирү оешмаларының уңай эш тәҗрибәсен тарату

Конкурс сайлап алуының бурычы: мәктәпкәчә яшьтәге балаларны билингваль белем бирүнең югары сыйфатын тәэмин итүче мәгариф оешмаларын ачыклау һәм бүләкләү.

## 2. Конкурс сайлап алуларын оештыру һәм үткәрү тәртибе.

2.1.Конкурс Министрлык боерыгы нигезендә үткәрелә.

2.2.Республика оештыру комитеты (алга таба-оештыру комитеты) рәис, рәис урынбасары, җаваплы сәркатиб һәм оештыру комитеты әгъзалары составында конкурс нигезендә сайлап алуны оештыру - методик яктан тәэмин итүне һәм уздыруны гамәлгә ашыра.

2.3.Оештыру комитеты составы грант бирүчеләр вәкилләреннән төзелә һәм Министрлык боерыгы белән раслана.

2.4.Оештыру комитеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

конкурс сайлап алуында катнашучылардан гаризалар кабул итү һәм теркәү;

эксперт комиссиясе составын туплау һәм раслау һәм аның эшен оештыру;

сайлап алу конкурсының турыдан-туры этабында катнашучылар составын раслау;

конкурс сайлап алуында җиңүчеләрне билгеләү һәм бүләкләү процедурасын оештыру;

эксперт комиссиясенең мәгариф оешмаларына чыгу графигын раслау;

конкурс сайлап алуын мәгълүмати тәэмин итү.

2.5.Оештыру комитеты утырышы, анда комитет әгъзаларының яртысыннан да ким булмаган өлеше катнашкан очракта, хокуклы санала. Оештыру комитеты карары, аның өчен катнашучыларның күпчелеге тавыш биргән очракта, кабул ителгән дип санала. Тавышлар саны тигез булганда оештыру комитеты рәисе тавышы хәлиткеч булып тора. Оештыру комитеты карарлары ачык тавыш бирү юлы

белән кабул ителә һәм беркетмә белән рәсмиләштерелә, рәис тарафыннан, ә ул булмаганда-оештыру комитеты рәисе урынбасары тарафыннан имзалана.

2.6.Грант бирүче, гаризалар кабул итү вакыты тәмамланырга 10 көннән дә соңга калмыйча, Министрлыкның рәсми сайтында «Интернет " мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә мәгълүмат урнаштыру юлы белән, конкурс сайлап алуын үткәрү турында игълан итә.

2.7.Грантка дәгъва кылучылар, конкурста катнашу өчен, 2018 елның 20 маена кадәр, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының мәгариф идарәсе (бүлеге) башлыгы тарафыннан расланган гаризаны министрлыкка, Казан шәһәре, Кремль урамы, 9 нчы йорт, 223 нче кабинет адресы буенча тапшыра, Гаризада мәгариф оешмасының исеме, адресы, җитәкченең элемтә өчен мәгълүматлары, белем бирү оешмасында тәрбия һәм укыту теле, төркемнәр һәм тәрбияләнүчеләр саны күрсәтелә.

Конкурс сайлап алуларының зона этабында катнашучыларның гаризаларын теркәү, конкурсның читтән торып һәм турыдан-туры сайлап алу этапларын оештыру, комитетының җаваплы секретаре тарафыннан башкарыла.

Гариза билгеләнгән сроктан соң бирелгән очракта, Грантка дәгъва кылучы конкурс сайлап алуында катнашу хокукын югалта.

2.8.Конкурс ике этапта үткәрелә:

читтән торып катнашу этабы - тәкъдим ителгән мәгълүмати материалларга эксперт бәясе;

турыдан-туры сайлап алу этабы - мәктәпкәчә яшьтәге балаларга билингваль белем бирү буенча грантка дәгъва кылучылар эшен бәяләү өчен эксперт комиссиясенең турыдан-туры белем бирү оешмаларына чыгуы.

Конкурс сайлап алуның читтән торып һәм турыдан-туры этапларын үткәрү вакыты Министрлык боерыгы белән раслана.

2.9.Конкурс сайлап алуның читтән торып үткәрелгән этабында катнашу өчен, грантка дәгъва кылучылар, министрлыкка гариза белән бергә билингваль белем бирү оешмасы эшчәнлегенең эчтәлеген чагылдырган мәгълүмати материаллар юллыйлар:

мәктәпкәчә яшьтәге балаларны ике телдә укыту оешмасы эшчәнлеге структурасы (балалар белән белем бирү эшчәнлеген оештыру формалары, тәрбияләнүчеләрнең ата-аналары белән хезмәттәшлек, педагоглар һәм башкалар белән эшләү.);

белем бирү оешмасының кадрлар белән тәэмин ителүе (штатта татар (рус) теленә өйрәтү буенча тәрбияче булуы, педагогларның мәктәпкәчә яшьтәге балаларга ике телдә тәрбия, белем бирү темасы буенча квалификация күтәрү курсларын узуы);

әлеге юнәлеш буенча эш системасын программа-методик, матди-техник тәэмин итү (шул исәптән педагогларның авторлык программалары булу, педагогларның эш тәҗрибәсен гомумиләштерү, төркемнәрнең, кабинетларның һәм башка төркемнәрнең әйләнә-тирә мохитен оештыру);

әлеге юнәлеш буенча эшнең нәтиҗәлелеге, тәрбияләнүчеләрнең һәм педагогларның казанышлары.

мәгълүмати материаллар 20 биттән артык булмаган күләмдә, басма рәвештә Word, шрифт Times New Roman,14. форматта бирелә. Кушымта (фотоматериаллар, дипломнар, автор эшләнмәләренә рецензияләр һәм тдп.) материаллары булу рөхсәт ителә.

2.10. Грантка дәгъва кылучыларның конкурс сайлап алу критерийларына туры килүенә экспертиза ясау өчен, эксперт комиссиясе рәисе һәм әгъзалары составында эксперт комиссиясе төзелә.

2.11.Эксперт комиссиясе составы оештыру комитеты тарафыннан раслана. Экспертлар сыйфатында грант бирүче, мәгариф идарәсе муниципаль органнары, педагогик хезмәткәрләрнең өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары, педагогик уку йортлары вәкилләре һәм мәктәпкәчә белем бирү оешмалары җитәкчеләре, педагоглары җәлеп ителергә мөмкин.

2.12.Экспертиза вакытында тәэмин ителәләр:

бәяләү критерийлары нигезендә белем бирү оешмасы эшчәнлеген бәяләүнең объектив булуы;

конфиденциальлек (шул исәптән, конкрет катнашучыны бәяләүдә катнашмаган эксперт комиссия әгъзаларына карата да).

2.13.Эксперт комиссиясе, конкурс сайлап алу этапларының элеге положение белән билгеләнгән, читтән торып һәм турыдан-туры этаплары критерийлары нигезендә, грантка дәгъва кылучыларга бәя бирә.

Һәр критерий буенча баллар эксперт кәгазьләренә кертелә, экспертлар имзасы белән раслана һәм оештыру комитетының җаваплы сәркатибенә тапшырыла.

2.14.Эксперт комиссиясе әгъзалары тарафыннан, сайлап алу конкурсының читтән торып үткәрелгән этабында һәр критерий буенча, белем бирү оешмасына куйган балларның суммасы нигезендә, грантка дәгъва кылучылырның рейтингы төзелә.

Конкурс сайлап алуларының турыдан-туры этабында читтән торып катнашу этабы нәтиҗәләре буенча рейтингта 1-45нче урыннарны алган грантка дәгъва кылучылар катнаша.

Оештыру комитетының сайлап алу конкурсының турыдан-туры этабында катнашучылар турындагы карары, оештыру комитетының җаваплы сәркатибе тарафыннан, билгеләнгән этапка кадәр 5 көннән дә соңга калмыйча, грантка дәгъва кылучыларга җиткерелә.

2.15.Эксперт комиссиясе әгъзалары конкурс сайлап алу этабының һәр критерие буенча белем бирү оешмасына куйган баллар суммасы нигезендә, турыдан-туры сайлап алу этабы нәтиҗәләре буенча грантка дәгъва кылучыларның рейтингын төзи.

Конкурс сайлап алуында җиңүчеләр булып, турыдан-туры сайлап алу этабы нәтиҗәләре буенча рейтингта 1 - 30 нчы урынга чыккан грантка дәгъва кылучылар таныла.

2.16. Конкурс сайлап алу нәтиҗәләре буенча, оештыру комитеты грант алучыларның, министрлык боерыгы белән расланган исемлеген төзи.

2.17.Грант алучыларның расланган исемлеге Минитрлык сайтында 2018 елның 30 июненә кадәр урнаштырыла.

## 3. Грант алуга конкурс сайлап алу критерийлары

3.1.Конкурсның читтән торып сайлап алу этабы критерийлары:

билингваль белем бирү эшчәнлеген оештыруга системалы якын килү (максималь баллар саны-10);

мәктәпкәчә яшьтәге балаларга билингваль белем бирү буенча эшчәнлекне ресурслар белән тәэмин итү (максималь баллар саны-10);

әлеге юнәлеш буенча белем бирү оешмасы тәкъдим иткән эш формаларының, балаларны дәүләт телләренә өйрәтү методикалары һәм технологияләренең төрлелеге һәм оригинальлеге, (максималь баллар саны - 10).

3.2.Конкурс сайлап алуының турыдан-туры этабы критерийлары:

балаларны дәүләт телләрендә укыту-методик комплектларын, этномәдәни региональ компонентны гамәлгә ашыру эшенең мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасында, укыту буенча, эшнең еллык планында, белем бирү оешмасының үсеш программасында чагылуы (максималь балл -5);

агымдагы уку елында мәктәпкәчә яшьтәге балаларга билингваль белем бирү белән бәйле тематика буенча төрле дәрәҗәдәге чаралар үткәрү (максималь баллар саны - 5);

телләргә өйрәтү һәм этномәдәни региональ компонентны гамәлгә ашыру бурычларын тормышка ашыру максатыннан кулланылган, балалар белән эшләү формаларының төрлелеге (максималь баллар саны - 5);

мәктәпкәчә яшьтәге балаларга билингваль белем бирү темасы буенча квалификация күтәрү узган педагогларның өлеше (максималь баллар саны-5);

педагогларның татар (рус) телләренә өйрәтү буенча укыту-методик комплектларның эчтәлеген белү дәрәҗәсе, методик компетентлылык (максималь балл-10);

әлеге юнәлеш буенча эшнең нәтиҗәлелеге, тәрбияләнүчеләрнең һәм педагогларның казанышлары (максималь баллар саны-10);

төркемнәрдә, кабинетларда этномәдәни региональ компонентны чагылдыра торган предметлы-үстерешле мохит булу, шул исәптән программа-методик материаллар белән тәэмин ителеш (максималь баллар саны-10);

белем бирү оешмасы эшендә авторлык программалары, мәктәпкәчә яшьтәге балаларга билингваль белем бирү буенча белем бирү оешмасы педагогларының методик эшкәртмәләре булу һәм куллану (максималь баллар саны - 5);

мәктәпкәчә яшьтәге балалар өчен билингваль белем бирү буенча ата - аналар белән эшләү формаларының системалылыгы һәм төрлелеге (максималь баллар - 5).

## 4. Грантны финанслау

4.1. Грант бирү максатларында субсидия бирү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.